**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**«17» октябрь 2019 ел** **№119**

**Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында**

Россия Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан республикасынын «Региональ салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 нче елнын 19 июлендэге № 54-ТРЗ карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль закон, «Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм җирле салымнар һәм җыемнар буенча чинга ашмаслык бурычларны түләттерүне җайга салу максаты белән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1.Түбәндәге нигезләр буенча недоимканы, пеня һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсезлекне тануның өстәмә нигезләрен билгеләү:

1) Гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны түләттерү өчен вакыт чыгу;

2) Гамәлдәге җирле салымнар буенча бурычларны түләттерү өчен, өч елдан артык вакыт узган, гомуми суммада 100(йөз) сумнан артмаган бурычларны түләтү өчен дәгъвалы вакыт чыгу;

3) 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы "Башкарма производство турында" гы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкарма битләр һәм суд боерыклары буенча физик затлардан җирле салымнар буенча бурычларны мәҗбүри түләттерү мөмкинлеге булмау;

4) Вафат булган физик затлар яисә федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә вафат булган затлар арасында варислары өч елдан соң мирас хокукы турында таныклык алмаган җирле салымнар буенча бурычлар.

2. 1,2,3,4 пунктында бәян ителгән карарны кабул итү өчен нигез булып түбәндәге шартлар тора:

1) Салым түләүченең җирле салымнар, недоимкалар, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычлар турында салым органының салым түләүченең урнашу урыны буенча салым органы белешмәсе булу;

2) Физик затның үлеме турында гражданлык хәле актын теркәү факты турында, гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән белешмәләр, я

гражданны билгесез дип игълан итү турында суд карары күчермәләре я гражданны вафат дип тану;

3) Үлгән көннән недоимка һәм (яки) пенялар һәм штрафлар, җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча бурычлары булган физик зат вафатыннан соң ачылган мирасны кабул итү турында гаризаларның булмавы хакында нотариус тарафыннан бирелгән белешмәләр;

4) "Башкарма производство турында"2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкарма җитештерүне тәмамлау турында суд пристав-башкаручысы карары күчермәләре.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренен рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе Х.Х. Ибәтов**